ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2024 Олы Кайбыч ав. № 273

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 апрелендәге 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 12.03.2024 елның 12 мартындагы 288 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 апрелендәге 211 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 15.2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм локаль системаларын куллануга даими әзерлектә булдыру, реконструкцияләү һәм тоту;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе Д.Ә. Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров